ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 23 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4; 2018, № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 1 өлешендә “законнарда” сүзен “Федераль законда” сүзләренә алмаштырырга;

2) 23 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Музей-тыюлык территориясенә су объекты, су объектының яр буе полосасы кишәрлеге керергә мөмкин, йә музей-тыюлык территориясе аның территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә тоташкан булырга мөмкин.”;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Музей-тыюлыкта булу кагыйдәләре музей-тыюлык тарафыннан билгеләнә һәм гражданнарга “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә музей-тыюлыкның рәсми сайтына, музей-тыюлыкка килүчеләрне кабул итүне оештыру зонасында, музей-тыюлык территориясендә алар күрә алырлык башка җирләрдә урнаштыру юлы белән җиткерелә.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

“$5^1$. Музей-тыюлыкта булу кагыйдәләренә шул исәптән түбәндәгеләр керә:

1) музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектыннан, су объектының яр буе полосасы кишәрлегеннән, шулай ук музей-тыюлык территориясе

чикләреннән читтә урнашкан, яр буе полосасы кишәрлегенә музей-тыюлык территориясе тоташкан су объектыннан файдалану үзенчәлекләре;

2) музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектына, су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә, шулай ук музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегенә керә алу үзенчәлекләре;

3) музей-тыюлык территориясендә һәм анда урнашкан объектларда музей-тыюлыкка килүчеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре;

4) музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегендә гражданнарның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре;

5) музей-тыюлыкка килүчеләр өчен кирәкле башка мәгълүмат.";

г) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ өлеш өстәргә:

"$6^1$. Музей-тыюлык территориясендә даими яшәүче гражданнар аның территориясе чикләрендә үз яшәешләрен тәэмин итә торган эшчәнлекне, шул исәптән музей-тыюлык территориясендә урнашкан су объектына, су объектының яр буе полосасы кишәрлегенә, шулай ук музей-тыюлык территориясе чикләреннән читтә урнашкан су объектының музей-тыюлык территориясенә тоташкан яр буе полосасы кишәрлегенә аларның ирекле керә алуын таләп итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга хокуклы. Музей-тыюлык территориясе чикләрендә аның территориясендә даими яшәүче гражданнарның әлеге территория өчен хас булган ысуллар белән башкарыла торган, шул исәптән су объектларыннан, аларның өлешләреннән файдаланып, электән билгеле булган эшчәнлек төрләрен саклап калуга юнәлдерелгән эшчәнлеккә рөхсәт ителә.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 05 апрель
№ 28-ТРЗ